СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле
авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Shur.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары**

**01 июль 2024 ел** **№ 94**

**«Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 4 июнендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 маендагы 300 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге уставы нигезендә, Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 4 июнендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәте өчен түләү турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт хакы түләү турында нигезләмәнең 1 пунктын (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары, депутатларның хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге - халык саны 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлек-хезмәткә түләүнең унберенче төркеменә карый.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары — И. Н. Габдрахманов

Иске Чүриле авыл
җирлеге Советының
01.07.2024 ел, № 94
карарына 1 нче кушымта

**Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәте өчен түләү турында нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү тәртибен билгели.

«Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затлары, депутатларның хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге -халык саны 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлек- хезмәткә түләүнең унберенче төркеменә карый.

2. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәт хакы акчалата түләү рәвешендә башкарыла:

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме (сум) |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы | 19 991 |

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләүдән тыш түбәндәгеләр түләнә:

-айлык акчалата бүләкләү;

- айлык хезмәт стажы өчен өстәмә;

-эш нәтиҗәләре буенча премия;

-еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;

- матди ярдәм;

-пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү.

4. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү елына 14.12 айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына хезмәте өчен акчалата түләүгә айлык өстәмә:

| Муниципаль вазыйфаларда хезмәт стажы өчен | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан күбрәк | 20 |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгының хезмәт стажы өчен айлык өстәмә түләүгә чыгымнар күләме елына өч айлык акчалата бүләкләүдән артмаска тиеш.

6. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче, җирле үзидарә органы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы затларга вазыйфа нструкцияләрендә һәм хезмәт килешүләрендә каралган бурычларны вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен премияләр түләү турында карар кабул ителгән көнгә җитәкчелек йөкләмәләрен, боерыкларын һәм күрсәтмәләрен вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен;

2) башка эшкә күчү, уку йортларына керү, квалификация күтәрү буенча курслар узу, санны яки штатны кыскарту буенча эштән азат ителү, пенсиягә чыгу, йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, өч яшькә җиткәнче бала карау һәм башка җитди сәбәпләр аркасында тулы булмаган вакыт эшләгән муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга премия түләү әлеге исәпләнгән чорда гамәлдә булган вакыт өчен башкарыла. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга, алар авыру сәбәпле эштә булмаган вакытта, премияләр түләү мәсьәләсе һәр тәгаен очракта яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан карала;

3) премия исәпләү өчен исәпләнгән чор дәвамында җирле үзидарә органына эшкә кергән затлар, аларның хезмәт кертемнәрен һәм гамәлдә эшләгән вакытын исәпкә алып, премиягә лаек була ала;

4) муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга премия календарь ел дәвамында хезмәт хакы фонды чикләрендә исәпләнә;

5) премияне исәпләү өчен хисап чоры буларак биремнәрне үтәү өчен билгеләнгән ай, квартал, ярты ел, ел яки башка вакыт кабул ителә;

6) премия суммасы максималь зурлык белән чикләнми;

7) муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче аерым затларга, аларның гомуми эш нәтиҗәләренә керткән шәхси өлешләрен исәпкә алып, премия күләме арттырылырга мөмкин;

8) муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче, производство хаталарына юл куйган һәм хезмәт дисциплинасын бозган затлар премиядән тулысынча яки өлешчә мәхрүм ителәләр.

Премиядән тулысынча яки өлешчә мәхрүм итү эшчәнлектә кимчелекләр ясаган һәм хезмәт дисциплинасын бозган хисап чорында башкарыла.

7. Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына бер айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә билгеләнә.

8. Матди ярдәм түбәндәгеләргә бәйле рәвештә түләнә:

-хезмәткәрнең баласы туу (һәр балага);

-хезмәткәрнең никахы;

- хезмәткәрнең юбилей яки башка истәлекле датасы (50, 55, 60, 65 яшь);

- хезмәткәрнең «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен» медале белән бүләкләнүе;

- хезмәткәрнең ире (хатыны), балаларының, әти-әнисенең үлеме;

- хезмәткәрнең катлаулы тормыш шартлары.

Матди ярдәм хезмәт хакы фондын экономияләү хисабына түләнә, түләү өчен нигез булып яллаучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

9. Пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә түләнә.

10. Акчалата бүләкләү, акчалата түләү, шулай ук айлык һәм башка өстәмәләр һәм түләүләр күләме арту ягына тулы сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш.